ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 406-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.Н. Шәфигуллин, Р.Р. Гайзатуллин, М.Һ. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 406-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 23 марты
№ 1898-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.Н. Шәфигуллин, Р.Р. Гайзатуллин,
М.Һ. Галиев тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 1 өлешнең 3 пунктында «законнарда» сүзен «Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында» сүзләренә алмаштырырга;
б) 2 өлештә:
беренче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;
4 пунктта «коммерциячел булмаган оешмалар, шул исәптән иҗтимагый берләшмәләр» сүзләрен «Россия Федерациясендә гавами хакимиятнең бердәм системасына керә торган башка органнар» сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяда «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында» 2012 елның 14 июлендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 7 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар

җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 пунктта «һәм иҗтимагый берләшмәләр» сүзләрен «, Россия Федерациясендә гавами хакимиятнең бердәм системасына керә торган башка органнар» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү максатларында әзерләнде.

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы, анда шул исәптән Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары һәм иҗтимагый берләшмәләр белән хезмәттәшлеген оештыру каралган, яңа редакциядә бәян ителә.

Кертелгән үзгәрешләр белән, аерым алганда, Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, Россия Федерациясендә гавами хакимиятнең бердәм системасына керә торган башка органнар белән хезмәттәшлеген оештыра дип беркетелә. Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты вәкаләтләренә карата шундый ук нигезләмә «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясында да бар.

Шуңа бәйле рәвештә закон проекты белән Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи затының кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү мәсьәләләре буенча һәм энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге вәкаләтләрен билгеләүче Татарстан Республикасы законнарының норматив нигезләмәләренә шундый ук үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Конституциясенә төзәтмәләр нигезендә закон проекты проектлана торган Татарстан Республикасы законнарының барлык текстында республиканың иң югары вазыйфаи заты исеменә үзгәрешләр кертүне күздә тота.

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнарны таләп итми.